МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 4.07.2019 Казан ш. № 333

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында**

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Канунының 48 нче маддәсе нигезендә, **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы журналистларның кушымтадагы аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

**Министр** **Ф.С.Габделганиев**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының 2019
елның 4 июлендәге 333 номерлы
боерыгы белән расланды.

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы журналистларның аккредитацияләү кагыйдәләре**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр «массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Канунының 48 нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү (алга таба – аккредитацияләү) тәртибен регламентлый.

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге белән аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган срокка, яки аккредитацияләнгән журналистны вакытлыча булмаган очракта (вакытлы аккредитация) алыштыру өчен башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитация хаккы

2.1. Аккредитация хаккына, милек формасына һәм гамәлгә куючыларның составына карамастан, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, ия. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аның аккредитациясенең Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы тарафыннан раслануы зарур.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитация алу гаризасы министрлыкка бирелгән гаризаның министрлык тарафыннан алынуы фактын, датасын һәм вакытын pасларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесенең имзасы өчен тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, эш һәм кесә телефоны номерлары, электрон почта адресы, тулы адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат

чарасының теркәлүе таныклыгының датасы һәм номеры.

Вакытлы аккредитация гаризасында шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, аккредитацияләнгән журналистның вакытлыча булмау сәбәпле алыштырган очракта исә - аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм алмаштыручы журналистны аккредитацияләү вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияне раслаучы документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация турында карар (аккредитацияне кире кагу турында) Татарстан Республикасы икътисад министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба-министр) тарафыннан гариза кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар министрның тиешле боерыгы чыккан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, редакция тарафыннан алынуы фактын, датасын һәм вакытын засларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән гаризаны юллаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслаштырылган характерга (реклама тарату, эротик басмалар) ия булса аккредитация кире кагылыр.

3.6. Гаризаларны карау, аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында министр боерыгы проектын әзерләү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм министрлыкның массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы тарафыннан башкарыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хаклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналист хаклары:

4.1.1. чарада катнашу;

4.1.2. министрлык карамагындагы чара турында рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

4.1.3. мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышу;

4.1.4. Россия Федерациясенең массакүләм мәгълүмат чаралары турында кануннары нигезендә башка хакларны гамәлгә ашыру;

4.1.5. Россия Федерациясе кануннарында каралган башка хаклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистларның бурычлары:

4.2.1. әгәр чара массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса, аның регламентын үтәү һәм барышына комачауламау;

4.2.2. чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламау;

4.2.3. Министрлык тарафыннан бирелгән матбугат релизларын, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны кулланганда мәгълүмат чыганагына сылтама ясау;

4.2.4. һөнәри эшчәнлеген башкарганда Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмау.